**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                                    КАРАР

_____________                                                                                    № ______

2022 елның 1 июленнән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән озынлыктан артып киткән тәнәфесләр белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында" Татарстан Республикасы Президентының "2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында" 15.12.2021 ел, ПУ-958 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында” 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

2022 елның 1 июленнән түбәндәгеләрне расларга һәм гамәлгә кертергә:

1. 2022 елның 1 июленнән расларга һәм гамәлгә кертергә: 1 нче кушымта нигезендә Актаныш муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар; 2 нче кушымта нигезендә муниципаль торак фондыннан торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме; 3 нче кушымта нигезендә торак биналарның милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен түләү күләме.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең "2021 елның 1 июленнән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында" 2021 елның 6 июлендәге пр-138 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районының икътисад буенча җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче урынбасары Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
________________ №____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| т/б | Түләү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт берәмлеге өчен тариф-сумнарда |
|---|---|---|---|
| | | | Актаныш күпфатирлы йортлар |
| | Торак бина өчен түләү | | |
| 1 | Торак бинаның капиталь ремонты | б./кв.м. | 6,38 |
| 2 | Торак урын наймы | б./кв.м. | 6,38 |
| 3 | Торак йорт белән идарә итү | б./кв.м. | 3,26 |
| 4 | Йорт яны территориясен җыештыру | б./кв.м. | 3,85 |
| 5 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | кв. м./сум | 4,00 |
| 6 | Сантех челтәрләрне агымдагы ремонтлау | б./кв.м. | 1,87 |
| 7 | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв. м./сум | 0,92 |
| 8 | Дератизация | б./кв.м. | 0,19 |
| 9 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә хезмәт күрсәтү | кв. м./сум | 0,28 |
| 10 | Торак йортны карап тотуга электр белән тәэмин итү | кв. м./сум | 0,70 |
| 11 | каты көнкүреш калдыкларын чыгару | ай/кеше | 111,55 |
| 12 | Үзәк җылыту системасына (Механизаторлар 7, Төзүчеләр 3) агымдагы ремонт | кв. м./сум | 1,41 |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
_______________ №____
2 нче кушымта

Муниципаль торак фондыннан торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме

| т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәм | Түләү күләме |
|---|---|---|---|
| | | | 01.07.2022 елдан |
| 1. | Найм буенча база ставкасы | аена торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. өчен | 6,38 |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
________________ №____
3 нче кушымта

Торак биналарның милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен түләү күләме

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| Капиталь ремонт | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 6,38 |